ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.06.2021 Олы Кайбыч ав. № 220

Җәйге чорда Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә
тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча
туктатып тору турында

Җәйге чорда балаларның аз йөрүен исәпкә алып, мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә ремонт эшләрен башкару зарурлыгы һәм бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 1 июленнән 31 августына кадәр вакытлыча җәйге чорга ябарга:
- ТР Кайбыч муниципаль районының «Р.Кәлимуллин исемендәге Борындык төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ (мәктәпкәчә төркем);
- «ТР Кайбыч муниципаль районының Ульянково төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ -«Надеждино «Земляничка» балалар бакчасы»;
- «ТР Кайбыч муниципаль районының Олы Урсак төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ(мәктәпкәчә төркем);
- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай балалар бакчасы» МБМББУ;
- «ТР Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ(мәктәпкәчә төркем);
- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки «Чулпан» балалар бакчасы» МБМББУ;
- «ТР Кайбыч муниципаль районының Мөрәле төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ(мәктәпкәчә төркем);
- ТР Кайбыч муниципаль районының «М.К.Кузьмин исемендәге Иске Тәрбит урта» гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ (мәктәпкәчә төркем);
- «ТР Кайбыч муниципаль районының Ульянково төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ -«ТР Кайбыч муниципаль районы Ульянково «Солнышко» балалар бакчасы»;
- «ТР Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән «Аленушка» балалар бакчасы» МБМББУ;

- «ТР Кайбыч муниципаль районының Иске Чәчкаб төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ(мәктәпкәчә төркем);

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Чүти «Буратино» балалар бакчасы» МБМББУ.

2. 2020 елның 1 августыннан 31 августына кадәр вакытлыча җәйге чорга ябарга:

- «ТР Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье «Каенкай» балалар бакчасы» МБМББУ;

- «ТР Кайбыч муниципаль районы Олы Тәрбит «Карлыгач» балалар бакчасы» МБМББУ;

- «ТР Кайбыч муниципаль районының Колаңгы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ(мәктәпкәчә төркем);

- «ТР Кайбыч муниципаль районы Кече Кайбыч «Сандугач» балалар бакчасы» МБМББУ.

3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгына:

3.1. педагогик хезмәткәрләргә һәм техник персоналга узган уку елы өчен чираттагы отпускларны бирүне;

3.2. педагогик хезмәткәрләргә һәм техник персоналга, мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең җәйге чорда чираттагы отпусклар тәмамланганнан соң ябылуына бәйле рәвештә, хезмәт хакын сакламыйча гына отпуск бирүне тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ һәм Кайбыч муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә җәйге чорга тәрбияләнүчеләрне кабул итүне туктатып торганда Мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр тарафыннан аларда тәрбияләнүчеләрне кабул итүне вакытлыча туктатып тору чорына мәктәпкәчә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү тәртибенә таянып эш итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы
Башкарма комитет Җитәкченең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина